**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"17 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында этаплы халык җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) парк территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үлән чабу, агач һәм куаклар утырту);

4) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

5) Түбән Бәрәскә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

6) Түбән Бәрәскә авылы Ленин урамында янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476